Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авылСоветы

КАРАРЫ

14 декабрь 2023 ел №92

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлеге территориясендә җирсалымыт урында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2013 елның 25ноябрендәге 78номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге икенче өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә,

Иске Михайловка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 78 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 113 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 130 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 85 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 5 номерлыкарарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары билгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлекләреннән тыш) яисә эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 процент.

2.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 1а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуныавыл Советы башлыгына йөкләргә.

Иске Михайловка авыл
җирлеге башлыгы А.Ю.Зарубин